Саранск гомуми белем бирv начар ишетvче балалар интернат-мәктәбе 2018-19 елларда тормышка ашырыла торган 1,5 миллион сумнан торган «Авыр тормыш хәлендә калган балалар» фонды проекты грантын яулаганнар. Максаты – профессия сайлауда остазлык-наставничество. Проект кысаларында мастер-класслар, класстан тыш чаралар, Мордовия производстволарында булу каралган, музейларга экскурсияләр булыр. Шулай, алар очен Инсар районы «Сармич» белән Ельник районы «Глубинка» май-сот эшкәртv заводларында, Кочкурово районы «Норов» белән Старошайгово районы предприятие-ләренә экскурсияләр оештырдылар. Һонәри юнәлеш бирv чарасы барышында укучылар авыл хужалыгында кирәкле һонәрләр белән таныштылар. Мәсәлән, укучыларнын экскурсия маршрутында беренче булып «Норовское молоко»нын Кочкурово бvлекчәсе булдылар. Биредә балаларга терлекчелек фермасынын ничек оештырылуы, сыерларнын нинди шартларда тотылуы турында сойләделәр һәм кvрсәттеләр. Алар сыерларны ашату процессын кvзәттеләр, саву залында булдылар. Мона кадәр кvпчелек балалар терлекче эшен кvз алдына да китермәде, бер тапкыр да терлекчелек фермаларында булмаганнар; доресен генә әйткәндә, кайбер укучы аларны телевизордан гына танышканнары булган. Шуна кvрә аларнын фермада кvргәннәре кызыксыну уятты һәм бераз гажәпләндерде: сыерларнын сәламәтлеге һәм савым процессы компьютер тарафыннан контрольдә тотыла. Аннары экскурсантлар Красномайский бистәсенә «Норовский» ит эшкәртv комплексына юл тоттылар. Балаларны эшкәртv цехлары буенча vткәрделәр, колбаса эшләнмәләре житештерv этапларын кvрсәттеләр, ә аннары предприятие продукциясен дегустацияләvдә катнашырга чакырдылар. Экскурсиянен сонгы пункты «Норов» агрофирмасынын орлык заводы булды. Укучылар кырлардан китерелгән кукурузны эшкәртvләрен кызыксынып кvзәттеләр, аннары киптерv бvлеген һәм орлык материалы саклана торган складта булдылар.

- Заманча авыл хужалыгы предприятиесендә булу балаларга бик кызык булды,- ди интернат-мәктәпнен физика укытучысы һәм класс житәкчесе Роза Мухаметжан кызы Абсалямова. - Теориядә, әлбәттә, терлекчелек фермаларында нәрсә белән шогыльләнvләрен кvз алдына китерәләр укучыларыбыз, ләкин vз кvзләре белән кvрv – ботенләй башка хис-тойгылар! Кvп нәрсә белән аерылып тора торган бvгенге предприятияләр һәм аларда булу элекке искергән стереотипларны юкка чыгарды. Укучылар бик кvп яна һәм файдалы мәгълумат алдылар, авыл хужалыгында эшләv vзенчәлекләрен билгеләп vттеләр. Бу экскурсия балаларнын кvзаллауларын кинәйтv очен бик файдалы, бәлки аларнын кайберләренә булачак һонәр сайларга ярдәм итәр дип уйлыйм.

**Наилә Насырова**